| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**11.07.2017 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1923** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 25 июлендәге 1557 номерлы карары белән расланган, «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының 2017 елның 09 июнендәге «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» под-1049/17 номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 25 июлендәге 1557 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 09.10.2015 № под-9409/15, 04.12.2015 № под-9682/15 боерыкларына кертелгән үзгәрешләр белән) «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

3.7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Мөрәҗәгать итүченең Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта өстенлекле рәвештә кучерелергә хокукы булган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә Зеленодольск

муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә ташламаны раслый торган документларны, шулай ук аларның күчермәләрен тапшырырга кирәк.

3.7.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга: «Ташламага ия булган категроиядәге гражданнар баланы бер Оешмадан икенчесенә күчергән вакытта Федераль закон, ТР законнары һәм башка норматив- хокукый актларда билгеләнгән ташламалардан файдалана.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин